**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » май 2020 с. Тюлячи № 219

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 апрелендәге 175 номерлы «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 апрелендәге 175 номерлы «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренә:

А) 1 пунктның беренче абзацыннан соң «өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләү өчен, ул торак урынны өлешле төзелеш объекты буларак эскор счетына тиешле акчалар кертү юлы белән (алга таба - өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе бәясен түләү);» сүзләрен өстәргә;

Б) 3 пунктта «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга, «карарлар» сүзен «боерыклар» сүзенә алмаштырырга;

В) 13 пунктта «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 14 пунктта «14 пункт» сүзләрен «13 пункт» сүзләренә алмаштырырга;

Д) 17 пунктта «торак-көнкүреш комиссиясе» сүзләрен «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

Е) 18 пунктта:

«Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга;

- «Башкарма комитет» «сүзләреннән соң әлеге яшь гаиләне Программада катнашучылар исемлегенә кертү турында» сүзләрен өстәргә;

Ж) 20 пунктның «б» пунктчасында «15» санын «13» санына алмаштырырга;

З) 21 пунктта:

- «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

«Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга;

- пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Яшь гаиләне социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлегенә кертү турында Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көне эчендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны тану турындагы карары нигезендә кабул ителә.»;

И) 22 пунктта:

- «Башкарма комитетның инфраструктур үсеш бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә тиешле килештә алмаштырырга;

- өченче абзацта «15» санын «13» санына алмаштырырга;

К) 24 пунктның «в» пунктчасының беренче һәм өченче абзацларында «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

Л) 26 пунктта «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

М) 28 пунктны түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«28. Җирле үзидарә органы, социаль түләүләр бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүгә каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәр алганнан соң, хәбәр итү фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирә торган ысул белән, тиешле елда социаль түләү алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләргә таныклык алу өчен документлар бирү кирәклеге турында хәбәр җибәрә, шулай ук әлеге таныклык буенча бирелә торган социаль түләүне алу һәм куллану тәртибен һәм шартларын аңлата.

Социаль түләү алуга хокук турында таныклык алу өчен яшь гаилә - социаль түләүгә тиешле елда социаль түләүгә дәгъва кылучы, социаль түләүгә хокук турында таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә алганнан соң 15 эш көне эчендә мондый таныклык (ирекле рәвештә) бирү турында гариза һәм әлеге Кагыйдәләрнең 5 номерлы кушымтасында күрсәтелгән документларны даими яшәү урыны буенча җирле үзидарә органына җибәрә.

Гаризада яшь гаилә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда социаль түләү алуга язма ризалык бирә.

Теләче муниципаль районы башкарма комитеты әлеге документлардагы мәгълүматларны тикшерү эшен оештыра.»;

Н) 29 пунктның беренче, өченче абзацларында «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

О) 32 пунктта «Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге» сүзләрен «Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

П) «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренә түбәндәге эчтәлектәге 6 номерлы кушымта өстәргә:

«2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренә 6 номерлы кушымта»

РАСЛЫЙМ

___________________________________

(Комиссия җитәкчесе вазыйфасының тулы исеме)

___________________________________

(Комиссия җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының имзасы)

«____»_____________ 20__ ел

КАРАР

«2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләрне тану (танымау) турында

Яшь гаилә ___________________«____» ___________ 20__ ел ______ сәгаттә, аны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында гариза бирде.

Яшь гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин ителеше:

| № т/б | Туганлык мөнәсәбәтләре | Ф.И.А.И. | Биләнелгән гомуми мәйдан (кв. м, адрес) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | милек хокукында | социаль наем шартнамәсе буенча | теркәлү урыны буенча | барлыгы |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Гаилә әгъзаларының торак шартларын бәяләү нигезендә ______________________________ гаиләсе «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаилә дип танылды/танылмады (кирәкмәсен сызарга) һәм «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасында катнашучылар исемлегенә кертелде/кертелмәде (кирәкмәсен сызарга)

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ (вазифаның исеме) | ______________________ (имза) | ______________________ (имзаның расшифровкасы) |
| ______________________ (вазифаның исеме) | ______________________ (имза) | ______________________ (имзаның расшифровкасы) |
| ______________________ (вазифаның исеме) | ______________________ (имза) | ______________________ (имзаның расшифровкасы) |
| ______________________ (вазифаның исеме) | ______________________ (имза) | ______________________ (имзаның расшифровкасы) |

«____» __________ 20__ ел».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов